
# Дәреснең темасы:


# «Процент»



# Сорауларга җавап бирегез

Процент дип нәрсә атала?

# Йөздән бер өлешне ПРОЦЕНТ дип атыйлар.



1 шакмак- $\frac{1}{100}$

$$\frac{1}{100} =$$

# Унарлы вакланманы процентка ничек әйләндерәләр?

Унарлы вакланманы процентка әйләндерү өчен, аны 100 гә тапкырларга кирәк.

# Процентны унарлы вакланмага ничек күчерергә?

Процентны унарлы вакланмага күчерү өчен, процентлар санын 100 гә бүләргә кирәк.

процентларда [illegible]

| | |
|---|---|
| | Жаваплар: |
| 0,08 = | 0,08=8% |
| 0,34 = | 0,34=34% |
| 6,5 = | 6,5=650% |
| 1,01 = | 1,01=101% |
| 0,002 = | 0,002=0,2% |
| 0,05 = | 0,05=5% |
| 54,5 = | 54,5=5450% |

# Процентны унарлы вакланма рәвешендә күрсәтегез:

3 % =

12 % =

2,5 % =

39 % =

0,7 % =

6 % =

126 % =

Җаваплар:

3%=0,03;

12%=0,12;

2,5%=0,025;

39%=0,39;

0,7%=0,007;

6%=0,06;

126%=1,26.

Мәсьәлә төрләре

I. Санның процентын табу

II Процент буенча санны табу

III Саннарның процентлы бәйләнешен табу

Бу мәсьәләләрне чишү өчен чишү программаларын искә төшерик

1.Процентны унарлы вакланма рәвешендә күрсәт.
2.Бирелгән санны килеп чыккан унарлы вакланмага

II
1.Процентны унарлы вакланма рәвешендә күрсәт.
2.Бу санны килеп чыккан унарлы вакланмага бүл

III
1. а санын в санына бүлергә.
2. Килеп чыккан өлешне 100 гә тапкырларга.

# Беренче мәсьәлә. Санның процентын табу буенча.

1. Предприятие бер кварталда 500 насос эшләп чыгарды, аларның 60 % ы югары сыйфатка ия. Предприятие югары сыйфатлы ничә насос эшләп чыгарган? (№1569)

Чишелеш:
60 % =0,6
500 x 0,6=300 (насос)
Җавап: 300 югары сыйфатлы насос.



# Процент буенча санны табу

2. Аю баласының массасы ак аю массасының 15 % ын тәшкил итә. Аю баласының массасы 120 кг булса, ак аюның массасын табыгыз. (№1577)

Чишелеш:

15%=0,15

120:0,15=800(кг)

Җавап: 800 кг.



# Саннарның процентлы бәйләнешен табу

3. Туристка 80 км юл үтәргә кирәк. Көн азагына ул 20 км юл үткән. Турист барлык юлның ничә процентын үткән?

Чишелеш:
20:80=0,25
0,25=25%
Җавап: 25 %.



# Ташламалы сату.
# Бәяләр 10% ка арзан.

Куелган бәяләрне үзгәртергә кирәк.

~~300~~сум — 270 сум

~~100~~сум — 90 сум

~~200~~сум — 180 сум

~~400~~сум — 360 сум



# Хәзер тестлар чишәбез!